| АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2019 п.г.т. Алексеевское №240

**ТатарстанРеспубликасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**контроль-хисап палатасы турындагы**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры килү, "Субъектлар һәм муниципаль берәмлекләр контроль-хисап органнарын оештыруның һәм алар эшчәнлегенең гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 7 нче маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында"гы 27 декабрь, 2018ел, 559-ФЗ санлы Федераль законга, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы Федераль законның 13 нче маддәсенә туры китереп,Алексеевск районыпрокуратурасының 15 апрель,2019 ел, 02-01-17-2019 нчы мәгълүматы нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районыконтроль-хисап палатасы турындагы НигезләмәгәТатарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районыАлексеевск район Советының 28 октябрь, 2011 ел, 132 нче карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 нче маддәнең 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.Россия Федерациясе гражданы түбәндәге очракта контроль-хисап палатасы рәисе һәм аның урынбасары итеп билгеләнә алмый:

1) аныңхөкем ителүе юкка чыгарылмаган яисә кире алынмаган булмаса;

2) законлы көченә кергән суд карары нигезендә аны эшкә яраксыз яки чикләнгән яраклы дип таныганда;

3) дәүләт серен һәм федераль закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга рөхсәтне рәсмиләштерүдән баш тарту, әгәр граждан дәгъва итүче вазыйфага керә торган бурычларны үтәү андый мәгълүматларны файдалану белән бәйләнгән булса;

4) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яки чит дәүләт гражданлыгын яисә яшәү урыннарында теркәлүгә рөхсәт кәгазе яки Россия Федерациясе

гражданының чил ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу;

5) әлеге маддәнең 3 нче өлешләрендә каралган сәбәпләрнең булуы.

6 маддәнең 3 нче пунктын түбәндәне редакциядә бәян итәргә:

"3. Контроль-хисап палатасы рәисе, аның урынбасары һәм аудиторлары вазыйфасын башкаручы гражданнар тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле хакимият башлыгы, суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганнар яки үги туганнар (ата-аналар, ир белән хатын, аларның берәрсенең балалары, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук ир белән хатынның, балаларының ирләре яки хатыннарының ир туганнары, кыз туганнары, аларның ата-аналары) булырга тиеш түгелләр.

2.Әлеге карарныАлексеевскмуниципаль районының рәсми сайтында, ТатарстанРеспубликасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм мәгълүмати-телекоммуникационИнтернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Совет рәисе урынбасары Г.В. Беловага йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**